ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 30 » сентябрь 2016 ел** **№19**

## Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Яңа Кырлай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге; | - юлларга вак таш салу.: Яңа Кырлай авылы, Тукай урамы, 70тән 95кә кадәр; Яшел урамы, Яшьләр урамы; | 91200 |
| | | Яңа Иябаш авылы, Татарстан ур., Яшьләр ур.; | 100000 |
| | | Өчиле авылы, Яңа ур., Җиңүнең 65 еллыгы ур.; | 48600 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Чиканас авылы, Совет ур., Октябрь ур., 27-51;<br>Иске Юрт авылы, Аркылы ур., Клуб ур.;<br>Югары Бирәзә авылы, Комсомол ур., Бахча-Сарай ур.;<br>Күкчә-Бирәзә авылы, Үзәк ур., 1-11, Починок ур. | 59500<br>25300<br>41200<br>15300 |
| | | | 382200 |

әйе

юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 йорт,Өчиле авылы, Тукай ур., 73 йорт.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров